ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.04.2025 г.Казань № 92/2025

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.08.2022 ел, №554/2022 боерыгы белән расланган Электр энергетикасында бәяләр (тарифлар) билгеләү, электр энергиясен гарантияле төстә җибәрүчеләр өчен электр энергиясен сату бәяләренә өстәмәләр билгеләү буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актын актуальләштерү максатларында

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.08.2022 ел, №554/2022 боерыгы (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 29.06.2023 ел, №476/2023 боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Электр энергетикасында бәяләр (тарифлар) билгеләү, электр энергиясен гарантияле төстә җибәрүчеләр өчен электр энергиясен сату бәяләренә өстәмәләр билгеләү буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтадагы үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
02.04.2025 № 92/2025
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.08.2022 ел, №554/2022 боерыгы белән расланган Электр энергетикасында бәяләр (тарифлар) билгеләү, электр энергиясен гарантияле тәстә җибәрүчеләр өчен электр энергиясен сату бәяләренә өстәмәләр билгеләү буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр**

2.4.1 пунктының беренче һәм икенче абзацларында «20 декабрьдә» сүзләрен «1 декабрьдә» сүзләренә алмаштырырга;

2.4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.2. Элек аларга карата тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган оешмалар өчен бәяләр (тарифлар), территориаль челтәр оешмалары белән исәп-хисаплар өчен электр энергиясен тапшыру хезмәтләрен күрсәтүгә индивидуаль бәяләрдән (тарифлардан), система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмалары арасында исәп-хисаплардан һәм бердәм илкүләм (Гомумроссия) электр челтәре буенча электр энергиясен тапшыру хезмәтләрен күрсәтүгә бәяләрдән (тарифлардан) тыш, нигезләүче материаллар Дәүләт комитетына кергән көннән алып 30 көн эчендә (әгәр гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән, почта аша яисә «Электрон Татарстан» электрон документ әйләнеше системасы аша тапшырылган булса) яки гаризага Порталда шәхси кабинетта чагылдырыла торган (әгәр гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан Порталдагы шәхси кабинет аша бирелгән булса) эшләр номенклатурасы һәм «Документларны тикшерү» статусы нигезендә номер бирелгән көннән алып 30 көн эчендә тулы күләмдә билгеләнә. Дәүләт комитеты карары буенча күрсәтелгән срок 30 көннән дә артмаска мөмкин.»;

2.6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.2. Мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына мөрәҗәгать иткәндә гариза белән бергә түбәндәге документларны тапшыра:

1) электр энергиясе балансы;

2) электр егәрлеге балансы, шул исәптән билгеләнгән, урнаштырылган, кулланылышта булган һәм эшләп торган генерацияләү куәте турында мәгълүмат;

3) җылылык энергиясенә карата ихтыяҗ һәм тәкъдимнәр балансы (катнаш эшләп чыгару режимында электр һәм җылылык энергиясен җитештерүне гамәлгә ашыручы электр энергетикасы субъектлары өчен);

4) җылылык егәрлеге балансы;

5) алдагы җайга салу чорында бухгалтерлык һәм статистика хисаплылыгы;

шәхси һәм производство ихтыяҗларына һәм челтәрләр буенча тапшыруга (югалтуларга) электр энергиясен тоту күләмен нигезләп, электр һәм җылылык энергиясен файдалану җибәрү исәпләмәсе (җылылык энергиясе өлешендә – катнаш эшләп чыгару режимында электр һәм җылылык энергиясе җитештерә торган электр энергетикасы субъектлары өчен);

7) бер урыннан икенче урынга алып баруны исәпкә алып, кулланыла торган ягулык структурасы һәм бәяләре турында белешмәләр;

8) Монополиягә каршы федераль хезмәт тарафыннан раслана торган методик күрсәтмәләр нигезендә эшләнгән икътисадый нигезләнгән беренчел белешмәләрне теркәп (кулланыла торган нормаларны һәм исәпләмә нормативларын күрсәтеп), җайга салынулы эшчәнлекне гамәлгә ашыруга чыгымнар һәм кирәкле тулай табыш исәпләмәсе (шул исәптән электр челтәрләренә технологик ялгауга бәйле, алынмый калачак керемнәрне билгеләү буенча Монополиягә каршы федераль хезмәт тарафыннан раслана торган методик күрсәтмәләр нигезендә билгеләнә торган, чынлыкта алынмый калачак керемнәр исәпләмәсе);

9) электр һәм җылылык энергиясе базарларында күрсәтелә торган аерым хезмәтләргә тарифлар исәпләмәсе;

10) заем капиталын турыдан-туры финанслау һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле акчага ихтыяҗ булуын нигезләп, инвестиция программасы (инвестиция программасы проекты);

11) мондый программаларны эшләү Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, энергияне сак тоту программасының билгеләнгән таләпләре нигезендә эшләнгән программалары;

12) рәсми статистика һәм бухгалтерлык хисаплылыгы нигезендә яисә җайга салынулы эшчәнлек алып бара торган оешмаларның хуҗалык эшчәнлеген тикшерү нәтиҗәләре нигезендә ачыкланган икътисадый нигезләнмәгән чыгымнарны (керемнәрне), тарифлар составында исәпкә алынмаган чыгымнарны, алдагы җайга салу чорында җайга салынулы оешмага бәйле булмаган сәбәпләр буенча алынмый калган керемне, шул исәптән алдагы җайга салучорында электр энергиясеннән килешүдән башка гына файдаланган затлар тарафыннан килешүдән башка гына кулланылган электр энергиясенең ачыкланган күләме бәясен түләттерү нәтиҗәсендә челтәр оешмасының барлыкка килгән өстәмә керемнәрен бәяләү;

13) җайга салынулы эшчәнлекне гамәлгә ашыруны (фактта яки планлаштырыла торган) раслаучы документлар, – эшчәнлек алып бару өчен файдаланыла торган объектларга карата милек хокукын яки башка законлы нигезләрне раслый торган документлар һәм җайга салынулы эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешүләр (юридик затны үзгәртеп корганда – тапшыру актлары);

14) кулланучының энергияне сак куллану һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, аның өчен исәпкә алу приборларын урнаштыру белән бәйле челтәр оешмасы чыгымнарын түләү бурычын раслаучы түбәндәге документларның берсе:

электр энергиясен исәпкә алу приборын урнаштыру шартларын җайга салучы, хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы һәм челтәр оешмасы арасында төзелгән килешү;

электр энергиясен исәпкә алу приборын урнаштыруга бәйле чыгымнарны мәҗбүри түләттерү турында законлы көченә кергән суд карары;

15) Интернет челтәрендәге рәсми сайтның һәм электр энергиясен тапшыру һәм (яки) технологик ялгау хезмәтләреннән файдаланучыларның мөрәҗәгатьләре өчен бүлеп бирелгән абонент номерының булуы турында мөрәҗәгать итүченең җитәкчесе яки башка вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган һәм мөрәҗәгать итүченең мөһере белән таныкланган белешмә (мөһер булган очракта);

16) трансформатор һәм башка подстанцияләрне, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр челтәрләре хуҗалыгы объектлары хуҗаларын территориаль челтәр оешмаларына кертү турында» 2015 елның 28 февралендәге 184 номерлы карары белән расланган электр челтәрләре хуҗалыгы объектлары хуҗаларын территориаль челтәр оешмаларына кертү критерийларының (алга таба – электр челтәре хуҗалыгы объектлары хуҗаларын территориаль челтәр оешмаларына кертү критерийлары) 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән электр тапшыру линияләрен билгеләп, мөрәҗәгать итүченең электр челтәрен тоташтыруның мөрәҗәгать итүченең җитәкчесе яки башка вәкаләтле заты тарафыннан расланган һәм мөрәҗәгать итүченең мөһере (мөһер булган очракта) белән таныкланган схемалары;

17) гаризалар һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 27 декабрендәге 861 номерлы карары белән расланган Электр энергиясе тапшыру хезмәтләреннән дискриминацияле булмаган нигездә файдалану һәм әлеге хезмәтләрне күрсәтү кагыйдәләренең 6(1) пунктында күрсәтелгән нигезләү материаллары, алар электро энергиясен күчергәндә файдаланылган электр челтәрләре хуҗалыгы объектларында барлыкка килгән электр энергиясен технологик югалту күләмендәге электр энергиясен югалтуларны компенсацияләү максатларында электр энергиясе (егәрлек) сатып алу чыгымнарына компенсация алу нияте булган электр челтәрләре хуҗалыгы объектлары милекчеләреннән яки башка законлы хуҗаларыннан территориаль челтәр оешмасына алынган очракта;

18) электр хуҗалыгы объектлары милекчесенең әлеге электр челтәрләре хуҗалыгы объектларын кулланып электр энергиясен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтә (күрсәтергә ниятли) торган оешмага карата төп яисә бүлендек (бәйле) җәймгыять булып торуы турында яисә электр челтәрләре хуҗалыгы объектлары милекчесенең һәм әлеге электр челтәрләре хуҗалыгы объектларын кулланып электр энергиясен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтә (күрсәтергә ниятли) торган оешманың шул бер үк җәмгыятькә карата төп яки бүлендек (бәйле) җәмгыятьләр булып торуы турында раслый торган белешмәләр, шулай ук оешманың электр челтәрләре хуҗалыгы объектлары хуҗаларын территориаль челтәр оешмаларына кертү критерияләренең 1 һәм 2 пунктларына туры килүен раслау максатлары өчен әлеге электр хуҗалыгы объектларына милекчелек хокукын раслый торган документлар;

19) территориаль челтәр оешмасының чит ил инвесторы (чит ил заты, затлар төркеме) контролендә булмавы турында гариза;

20) территориаль челтәр оешмасы белән затларның бер төркеменә керүче затлар исемлеге (кәгазь саклагычта һәм электрон таблица һәм электрон саклагычтагы график файл рәвешендә бирелә), мондый затларның затлар төркемен тәшкил итә торган нигезләрен күрсәтеп, Монополиягә каршы федераль хезмәт тарафыннан расланган затларның бер төркеменә керүче затлар исемлеген тапшыру формасы буенча;

21) түбәндәге исемлекләр:

җайга салынулы эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешманың устав капиталындагы өлешләренең (акцияләренең) 5 проценттан артыграгы белән турыдан-туры яисә читләтеп эш итү хокукына ия булган затлар исемлеге;

территориаль челтәр оешмасын турыдан-туры яки читләтеп контрольдә тотучы затлар, контрольдә тотучы затлар, бенефициар хуҗалар, файда алучы затлар күрсәтелгән исемлеге. Мондый оешманы тикшереп торучы затның бенефициар хуҗасы (файда алучы) Россия Федерациясе гражданины булса, аның Россия Федерациясе гражданлыгыннан гайре башка гражданлыгы, яшәүгә рөхсәте яисә чит дәүләттә даими яшәү хокукын раслый торган башка дөрес документының булуы (булмавы) турында мәгълүматны күрсәтергә кирәк (мәгълүмат күрсәтелгән Россия Федерациясе гражданинының үз кулы белән имзаланган гаризасы яисә вәкаләтле вәкил имзалаган гаризасы рәвешендә, мондый гаризаларны бирү хокукына ышанычнамәнең таныкланган күчермәләре һәм вәкаләтле вәкил паспорты күчермәләрен теркәп тапшырыла);

22) территориаль челтәр оешмасында катнашучының мөлкәткә ышанычлы идарә итү шартнамәсе, залог шартнамәсе, репо шартнамәсе, тәэмин итү түләве, мондый затның исемен яисә шәхси белешмәләрен, салым түләүченең идентификация номерын, аның урнашу урынын күрсәтеп башка килешү яисә алыш-биреш нигезендә территориаль челтәр оешмасының өлешләре (акцияләре) белән эш итү хокукын вакытлыча башка затка тапшыруы турында мәгълүмат (әгәр мондый зат Россия Федерациясе гражданины булса), шулай ук әлеге пунктның 21 пунктчасында каралган белешмәләр күрсәтелә);

23) мондый оешманың катнашучылары (акционерлары) хокукларын гамәлгә ашыру турында алар үз хокукларын билгеле бер рәвештә гамәлгә ашырырга һәм (яисә) күрсәтелгән хокукларны гамәлгә ашырудан тыелып торырга (баш тартырга), шул исәптән оешмада катнашучыларның (акционерларның) гомуми җыелышында билгеле бер рәвештә тавыш бирергә, тавыш бирү вариантын башка катнашучылар (акционерлар) белән килештерергә, өлешләрне (акцияләрне) яисә өлешләрнең (акцияләрнең) бер өлешен шундый шартнамәдә билгеләнгән бәядән сатарга һәм (яки) билгеле бер хәлләр килеп чыкканда өлешне (акцияне) яки өлешләрнең (акцияләрнең) бер өлешен билгеле бер хәлләр килеп чыкканчы читләштерүдән тыелырга (баш тартырга), шулай ук күрсәтелгән оешма белән идарә итүгә, мондый оешманы булдыруга, аның эшчәнлегенә, аны үзгәртеп оештыруга һәм бетерүгә бәйле башка гамәлләрне килештереп башкарырга йөкләмә ала торган, территориаль челтәр оешмасында катнашучылар (акционерлар) арасында шартнамә булуы турында мәгълүмат;

24) шартлары чит ил инвесторына (чит ил затына, затлар төркеменә) территориаль челтәр оешмасы кабул итә торган карарларны, шул исәптән мондый оешманың үз эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартларын билгеләү хокукы яисә вәкаләте бирә торган, төзелгән шартнамәләр, башка хокук билгеләүче документлар турында белешмәләр (алар булган очракта);

25) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Чит ил юридик затлары, юридик затлар булмаган чит ил оешмалары һәм алар контролендә булган оешмалар тарафыннан Россия Федерациясендә чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору

функцияләрен башкаруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына үзләренең файда алучылары, бенефициар хуҗалары һәм тикшереп торучы затлары турында мәгълүмат тапшыру кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 1 декабрендәге 1456 номерлы карары белән расланган Чит ил юридик затлары, юридик затлар булмаган чит ил оешмалары һәм алар контролендә булган оешмалар тарафыннан Россия Федерациясендә чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору функцияләрен башкаруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына үзләренең файда алучылары, бенефициар хуҗалары һәм тикшереп торучы затлары турында мәгълүмат тапшыру кагыйдәләре нигезендә территориаль челтәр оешмасын тикшереп торучы чит ил юридик затларының, юридик затлар булмаган чит ил оешмаларының файда алучылары, бенефициар хуҗалары һәм контрольдә тотучы затлары турында белешмәләр;

26) күрсәтелгән белешмәләрне раслый торган документлар белән, территориаль челтәр оешмасының идарә һәм контроль органнары турында белешмәләр (фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта), туу датасын, яшәү урынын, салым түләүченең индивидуаль номерын, Россия Федерациясе гражданлыгы турында мәгълүматны, башка гражданлыкның, яшәүгә рөхсәтнең яисә чит дәүләттә даими яшәү хокукын раслый торган башка дөрес документның булу-булмавы турында мәгълүматны, мондый органнарга керүче затларны күрсәтеп).

Берләштерү, үзгәртеп кору яки тоташтыру формасында юридик затларны үзгәртү нәтиҗәсендә барлыкка китерелгән җайга салуны оешма өчен бәяләр (тарифлар) билгеләнгәндә әлеге пунктның 5, 13, 14 пунктчалары нигезендә үзгәртеп корылган оешмага (үзгәртеп корылган оешмаларга) карата тапшырылган документлар һәм материаллар кулланылырга мөмкин.

Юридик затларны берләштерү яисә үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп кору нәтиҗәсендә барлыкка килгән җайга салынулы оешма тарафыннан шулай ук мондый оешманың дәүләт теркәвенә алу датасына бухгалтерлык хисабы тапшырыла.

Әлеге пунктның 5 пунктчасында күрсәтелгән бухгалтерия хисаплылыгы гаризага, әгәр ул «Хисапчылык исәбе турында» 2011 елның 6 декабрендәге 402-ФЗ номерлы федераль законның 18 статьясында каралган хисапчы (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсында булмаса, теркәлә. Җайга салына торган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешма бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсын формалаштыру максатларында бухгалтерлык исәплылыгын төзегән очракта, республиканың башкарма хакимият органнары ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасын кулланып, әлеге дәүләт мәгълүмат ресурсыннан шундый хисап ала.»;

2.6.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.6. Җайга салынулы эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар Дәүләт комитетына бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы тәкъдимнәргә үз инициативалары белән агымдагы җайга салу чорының 1 ноябреннән дә соңга калмыйча өстәмә материаллар тапшырырга хокуклы. Төгәлләштерелгән тәкъдимнәр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергиясенең күпләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары тарафыннан мәгълүматны ачу стандартларын раслау

турында» 2004 елның 21 гыйнварындагы 24 номерлы карары белән расланган Электр энергиясенең күпләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары тарафыннан мәгълүматны ачу стандартларында билгеләнгән тәртиптә ачылырга тиеш.»;

2.6.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.11. Элек тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган оешмалар өчен җайга салуның чираттагы һәм (яисә) агымдагы чорларына бәяләр (тарифлар) җайга салуның чираттагы чорына кадәрге елның 15 августына җибәрелгән нигезләү документлары белән бергә бәяләрне (тарифларны) билгеләү турындагы тәкъдим нигезендә исәпләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.6.12 пунктын өстәргә:

«2.6.12. Аларга карата тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган оешмалар, территориаль челтәр оешмалары белән исәп-хисаплар өчен электр энергиясен тапшыру хезмәтләрен күрсәтүгә индивидуаль бәяләрне (тарифларны) билгеләү максатларында, җайга салуның чираттагы исәп-хисап чоры башыннан җайга салуның чираттагы чорына кадәрге елның 15 августына кадәр теркәлә торган нигезләү материаллары белән җайга салу органына тәкъдим тапшыралар.»

2.8.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8.2. Эш ачудан баш тарту нигезләре:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергиясен күпләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларын раслау турында» 2004 елның 21 гыйнварындагы 24 номерлы карары белән расланган Электр энергиясен күпләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларында билгеләнгән тәртиптә җайга салынырга тиешле бәяләр (тарифлар) һәм җайга салуның озак сроклы параметрлары (инвестицияләнгән капиталның керемлелеге ысулын яисә кирәкле тулаем керемне озак срокка индексацияләү ысулын кулланганда) күләме турында язманың булмавы яисә күрсәтелгән бастырылган тәкъдимнең җайга салу органына тапшырыла торган тәкъдимгә туры килмәве;

территориаль челтәр оешмаларына карата җайга салуның чираттагы чорына кадәрге елның 1 сентябреннән соң оешманың электр челтәре хуҗалыгы объектлары хуҗаларын территориаль челтәр оешмаларына кертү критерийларына туры килмәвен билгеләү;

җайга салу органы тарафыннан җайга салынучы оешма тапшырган документлар нигезендә «Ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өчен стратегик әһәмияткә ия хуҗалык җәмгыятьләренә чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2008 елның 29 апрелендәге 57-ФЗ номерлы федераль законның 5 статьясындагы $1\text{-}2^{1}$ өлешләрендә каралган билгеләр нигезендә территориаль челтәр оешмасының чит ил инвесторы (чит ил заты, затлар төркеме) контролендә булуын билгеләү яисә җайга салу органына Россия Федерациясендә чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору функцияләрен башкаруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль челтәр оешмасының чит ил инвесторы (чит ил заты, затлар төркеме) контролендә булу фактын билгеләү турында бәяләмәсе керү;

элек аларга карата тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә

ашырылмаган оешма тарафыннан бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдимне җайга салуның чираттагы чорына кадәрге елның 15 августыннан соң тапшыру.

җайга салу органы тарафыннан җайга салынучы оешма тапшырган документлар нигезендә «Ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өчен стратегик әһәмияткә ия хуҗалык җәмгыятьләренә чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2008 елның 29 апрелендәге 57-ФЗ номерлы федераль законның 5 статьясындагы 1-2[1] өлешләрендә каралган билгеләр нигезендә территориаль челтәр оешмасының чит ил инвесторы (чит ил заты, затлар төркеме) контролендә булуын билгеләү яисә Россия Федерациясендә чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору функцияләрен башкаруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль челтәр оешмасының чит ил инвесторы (чит ил заты, затлар төркеме) контролендә булу фактын билгеләү турында бәяләмәсе керү очрагында, Дәүләт комитеты элегрәк ачылган эшне туктата.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.7.3 пункт өстәргә:

«3.7.3. Дәүләт комитеты, чит ил инвесторы (чит ил заты, затлар төркеме) контролендә территориаль челтәр оешмасының булмавы турындагы белешмәләрнең дөреслегенә нигезле шик булганда, әлеге Административ регламентның 2.6.2 пунктының 19-26 пунктчалары нигезендә җайга салынучы оешма тарафыннан тапшырылган документларның күчермәләрен теркәп, Россия Федерациясендә чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору функцияләрен башкаруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органыннан территориаль челтәр оешмасының чит ил инвесторы (чит ил заты, затлар төркеме) контролендә булу-булмавы турында сората.

Россия Федерациясендә чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору функцияләрен башкаруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль челтәр оешмасының чит ил инвесторы (чит ил заты, затлар төркеме) контролендә булу фактын билгеләү турындагы бәяләмәсе Дәүләт комитетына кергән очракта, җайга салучы орган бәя (тариф) билгеләү турында эш ачудан баш тарта яисә элек ачылган эшне туктата.»;

3.8 пунктта:

алтынчы абзацта «20 декабрьдә» сүзләрен «1 ноябрьдә» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үзләренә карата элегрәк тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган оешмалар өчен чираттагы һәм (яки) хәзерге җайга салу чорына бәяләр (тарифлар материалларны тапшыру срогына бәйсез рәвештә исәпләп чыгарыла. Күрсәтелгән оешмаларга карата бәяләр (тарифлар) җайга салу органына нигезләүче материаллар кергән көннән алып 30 көн эчендә тулы күләмдә билгеләнә, моңа территориаль челтәр оешмалары белән исәп-хисаплар өчен электр энергиясен тапшыру хезмәт күрсәтүләренә индивидуаль бәяләр (тарифлар), система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмалары арасында исәп-хисаплар һәм бердәм илкүләм (Гомумроссия) электр челтәре буенча электр энергиясен тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә бәяләр (тарифлар) керми. Җайга салучы орган карары буенча әлеге срок 30 көннән дә артмаска тиеш.»;

3.9.3 пунктның икенче абзацында «20 декабрьдә» сүзләрен «1 декабрьдә» сүзләренә алмаштырырга;

«Белешмәлек» кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан электр энергетикасында бәяләр (тарифлар) билгеләү, электр энергиясе белән гарантияле тәэмин итүчеләрнең сату өстәмәләрен билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты

| Фамилия, исем, ата исеме вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Рәис<br>Груничев Александр Станиславович | 8 (843) 221-82-18 | Kt@tatar.ru |
| Рәис урынбасары<br>Сапожников Дмитрий Аркадьевич | 8 (843) 221-82-80 | Dmitriy.Sapozhnikov @tatar.ru |
| Электр энергиясенә тарифларны җайга салу һәм тикшереп тору бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы<br>Ирина Юрьевна Суркова | 8 (843) 221-82-56 | Irina.Surkova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе җитәкчесе | 8(843) 264-77-22 | Renat.Gaynutdinov @tatar.ru |

Монополиягә каршы федераль хезмәт

Элемтә өчен телефон: 8 (499) 755-23-23, электрон адрес: delo@fas.gov.ru.»